КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 декабрь г.Казань № 1651

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы карары белән расланган Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәре үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәре үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 861 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәре үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен сайлау һәм үткәрү турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү рискын бәяләү максатларында мәҗбүри таләпләрне бозу рискының түбәндәге индикаторы билгеләнә:

шул ук чор өчен техник тикшерү үткәрелгән транспорт чаралары саны сакланган вакытта үткән календарь ел белән чагыштырганда календарь елга транспорт чараларының һәр категориясе яктылыгында техник тикшерүдән һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта бирүдән керә торган табышны ике һәм аннан күбрәк тапкырга арттыру яки аны иң күбе 5 процентка арттыру.»;

13 пунктта «риск индикаторлары» сүзләрен «риск индикаторы» сүзләренә алмаштырырга;

45 пунктның дүртенче абзацында «риск индикаторлары» сүзләрен «риск индикаторы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин